РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ САРДЕКБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘРДЕКБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422126, с.Сардек-Баш , Ул.Центральная , д.45 Тел./факс: (884364) 25-0-43 e-mail: Sard.Kuk@tatar.ru,

# КАРАР

15 июн 2022 ел №13

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советның аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (биләгән) затлар тарафыннан үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында» Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 апрелендәге 12 номерлы карары;
- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 апрелендәге 11 нче номерлы карары;
- Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 апрелендәге 11 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 июнендәге 10нчы номерлы карары;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат

стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: Нәбиев И.М.